КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 21 май г.Казань № б-1022

Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Урынбасары Т.А.Голикова тарафыннан расланган Гавами хакимиятнең барлык дәрәҗәләрендә 2026 – 2030 елларга «Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 651-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру буенча 2025 елның 5 декабрендәге ТГ-П45-46197 номерлы чаралар планын гамәлгә ашыру максатларында:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2026 – 2030 елларга Татарстан Республикасында инвалидларны һәм инвалид балаларны комплекслы реабилитацияләү һәм абилитацияләү системасын гамәлгә ашыру чаралары планын (алга таба – Чаралар планы) расларга.

2. Республика башкарма хакимият органнарына хисап елыннан соң килә торган елның 5 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Чаралар планын гамәлгә ашыру барышы турында мәгълүмат кертергә, шулай ук Чаралар планын гамәлгә ашыруда катнашучы оешмаларга аны кертүне тәкъдим итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин